**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Келәнче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**12 декабрь 2024 ел** **№ 121**

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә һәм «Җирләү эше өлкәсендә җирлекләрнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен (вәкаләтләр өлешен) тапшыру турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2024 елның 18 ноябрендәге 220 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнч еавыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнчеавыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы тәкъдимен кабул итәргә:

- җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру;
- җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү;
- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән Исемлеге хезмәтләре сыйфатына карата таләпләрне раслау;
- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау;
- ире, якын туганнары, бүтән туганнары йә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкин булмаганда, шулай ук эчке эшләр органнары тарафыннан мәрхүмне шәхесен ачыклаганнан соң аның өендә, урамда яисә башка урында җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда вафат булганнарны (һәлак булганнарны) күмү хезмәтләренең бәясен раслау;

- шәхесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда Эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән үлгәннәрне (һәлак булганнарны) күмүгә хезмәт күрсәтү бәясен раслау.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнчеавыл җирлеге башкарма комитетына: Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә; әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Келәнче авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Советы Рәисе Д.А.Кадыров.